**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«10 » 11 2025 ел №3680

«Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 2307 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 29 сентябрендәге 776 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне гамәлгә ашыру, Башкарма комитетның «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 2307 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 3.3.3 пунктында өстәргә:

«Хезмәтне алу өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмат запросларын җибәрергә кирәк:

1) «Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» мәгълүмат запросы. Күрсәтелгән мәгълүмат запросы, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, «Бердәм дәүләт граждан хәле актларын язулар реестры» сервисы яисә «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сервисы аша 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамә бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» мәгълүмат запросы. Күрсәтелгән мәгълүмат запросы, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, «Бердәм нотариат мәгълүмат системасы» сервисы аша 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Җитәкче урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов